**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 20 ноябрендәге 4723 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2011 елның 18 августындагы 4662 номерлы**
**«Гражданнарны торак урыннар алуда кичектергесез**
**ярдәмгә мохтаҗ дип тану турында»гы карарына**
**үзгәреш кертү хакында**

Гражданнарны Казан шәһәрендә һәркем ала алырлык торак белән тәэмин итү һәм Социаль ипотека программасы буенча торак урыннар алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ гражданнарның квоталарын рациональ файдалану максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 18 августындагы 4662 номерлы «Гражданнарны торак урыннар алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип тану турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 22 мартындагы 1810 номерлы, 2014 елның 22 августындагы 5075 номерлы, 2015 елның 27 октябрендәге 3786 номерлы, 2019 елның 19 февралендәге 593 номерлы, 2020 елның 5 июнендәге 1601 номерлы, 2021 елның 1 февралендәге 227 номерлы, 2023 елның 24 апрелендәге 1168 номерлы, 2023 елның 29 августындагы 2462 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымтасына, түбәндәге эчтәлектәге 3.8 пунктча белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«3.8. шәһәр пассажир транспорты йөртүчеләре, Казан шәһәре предприятиеләрендә хезмәт эшчәнлеген башкаручы махсуслаштырылган шәһәр җыештыру техникасы йөртүчеләре (механизаторлары)».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар**

**А.Р.Нигъмәтҗанов**